ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» 134-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Г.Н. Глушков, Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» 134-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 485-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Г.Н. Глушков, Л.А. Якунин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалтkан дип танырга:

1) «Уен бизнесына салым ставкалары турында» 2012 елның 24 февралендәге 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 2);

2) «Уен бизнесына салым ставкалары турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2017 елның 22 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш).

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану хакында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 425-ФЗ номерлы Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә әзерләнде.

Хәзерге көндә Россия Федерациясе Салым кодексының 14 статьясы нигезендә уен бизнесына салым Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле керемнәргә салына торган региональ салымнарга кертелгән. «Уен бизнесына салым ставкалары турында» 2012 елның 24 февралендәге 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Россия Федерациясе Салым кодексының 29 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә уен бизнесы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар өчен уен бизнесына салым ставкалары билгеләнә.

425-ФЗ номерлы Федераль закон белән 2026 елның 1 гыйнварыннан уен бизнесына салым, бер үк вакытта аны алу тәртибен үзгәртеп, региональ салымнардан федераль салымнарга күчерелә. Шуңа бәйле рәвештә, бу салымнан керемнәр тулы күләмдә федераль бюджетка күчереләчәк.

Федераль законнардагы әлеге үзгәрешләргә бәйле рәвештә, закон проекты белән «Уен бизнесына салым ставкалары турында» 2012 елның 24 февралендәге 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм «Уен бизнесына салым ставкалары турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2017 елның 22 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үз көчен югалткан дип танырга тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы закон проектына ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен алып бетермәүгә китерәчәк.

Татарстан Республикасы бюджетының алып бетерелмәгән керемнәре елга 5,5 млн сум күләмендә бәяләнә, алар букмекерлык контораларында һәм тотализаторларда комарлы уеннарны оештыручылар өчен кертелә торган оешмалар табышына салым белән компенсацияләнәчәк.